## ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

**«15» ноябрь 2023 ел № 1**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Түбән Аты авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,2023 елның 15 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Түбән Аты авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертү,шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (алар белән бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру
- Кече урамындагы чишмәгә материаллар сатып алу һәм ремонт эшләрен башкару;
- су күтәрү манарасының насос станциясе бинасы төзелеше
- җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл япмасын ремонтлау;
- мотопомпаны комплектлау белән сатып алу (янгын сүндерү култыгы, суырткыч култыгы, янгын сүндерү очлыгы)

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Халык җыены беркетмәсе(йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 326 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 187 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 187 кеше тавыш бирде; " Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлегендә Түбән Аты авылы халык җыенын узган һәм аның нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Тубән Аты авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертү,шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (алар белән бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру
- Кече урамындагы чишмәгә материаллар сатып алу һәм ремонт эшләрен башкару;
- су күтәрү манарасының насос станциясе бинасы төзелеше
- җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл япмасын ремонтлау;
- мотопомпаны комплектлау белән сатып алу (янгын сүндерү култыгы, суырткыч култыгы, янгын сүндерү очлыгы)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

« ӘЙЕ» -187 « КАРШЫ»-0

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Түбән Аты авылы, Үзәк урам, 37йорт; ТР, Арча районы, Түбән Аты авылы, Үзәк урам, 11Б адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Урта авыл җирлеге башлыгы Батталова Р.Х